Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 1 10 февраль 2015ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Ибрай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы белән , Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАРы:

• Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Сез Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма милеккә ия булган һәр 18 яшькә җиткән һәр кешедән 200 сум күләмендә 2015 елдан башлап үзара салым акчаларын бер тапкыр түләүне гамәлгә кертүгә килешәсезме?

Үзара салым акчалары тотыла торган төзекләндерү чаралары исемлеге:

1. Торак пунктларны төзекләндерү.
2. Зиратларны төзекләндерү.
3. Юлларны, күперләрне карап тоту һәм ремонтлау.
4. Чүп чыгару.
5. Хуҗасыз этләрне тоту.
6. Урам яктыртуны ремонтлау.

2. Сез Бөек Ватан сугышында катнашучылар, I һәм II теркем гомуми авыру инвалидлары өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне кертмәүне билгеләргә ризамы?

РИЗА КАРШЫ».

• Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълумати стендларында да.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Х.Кабиров